**Солтанова Фәриха Миндар кызы**



Солтанова Ф.Х. 1985 елда Алабуга дәүләт педагогик институтын тәмамлагач, башлангыч сыйныф укытучысы булып Яр Чаллы шәһәренең №11 мәктәбенә эшкә урнаша.

Ике ел хезмәт куйганнан соң, Фәриха Миндар кызы хәрби кешегә кияүгә чыгып, Ерак Көнчыгышка күченеп китә. 12 ел Приморье крае Дальнереченск шәһәрендә башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшли.

Кабат Мөслим районы Мөслим авылына кайткач, лицейга (ул вакыта Мөслим урта белем бирү мәктәбе) эшли башлый. Мәктәптә 20 ел эшләп, лаеклы ялга чыга.

Ялда булуына карамастан, тынгысыз Солтанова Ф.М. әле дә балалар белән эшли. Бүгенге көндә аның педагогик стажы – 35, гомуми стажы – 40 ел тәшкил итә. Тырыш хезмәте өчен мәгариф бүлеге идарәсе, Татарстан Республикасы мәгариф министрлыгынын мактау кәгазьләре, рәхмәт хатлары һәм дипломнары белән бүләкләнә.

“Мин укучыларымның әйткән кызыклы сүзләрен язып, рәсемнәрен җыеп барам. Куп вакытлар үтеп, очрашуга баргач, үзләренә кире биреп, кечкенә вакытларына кайтарырга яратам”, - ди Фәрихә Миндар кызы.